# Сүз ясалышы ысуллары

Янгирова Ләйсән Фирдәвес кызы,

Бөгелмә муниципаль районы

Муниципаль белем бирү учреждениесе

Кодаш төп гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы



*Саумы, кояш, саумы, көн!*
*Дусларым, хәерле көн!*
*Телим сезгә сәламәтлек,*
*Бәхет һәм яшәү дәрте.*
*Уе изге баласына*
*Булышыр табигать тә.*
*Эшкә тотыныйк, дусларым,*
*Хуш, хәерле сәгатьтә!*

# Тест җаваплары

1. 2
2. 3
3. 2
4. 1
5. 1
6. 2
7. 3
8. 3
9. 3
10. 3

# Сүз ясалышы ысуллары

| ? | ? | ? | ? | ? | ? | ? | ? |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гармунчы | башкала | күзгә-күз | Кара диңгез | хәзер – әзер | тамыр (тамыр) | уку (нәрсә?) - уку ( нишләү?) | ТР |
| күңелле | Илшат | аң-белем | Кара диңгез | та'ныш – таны'ш | пәрдә(пәрдә) | көтүче (кем?)- көтүче (нишләүче?) | КамАЗ |
| элмәк | алъяпкыч | килде-китте | калак сөяге | чачак – чәчәк | ай (ай) | биюче (кем?)- биюче (нишләүче?) | АКШ |


# Дәреснең максатлары:

1. «Сүз ясалышы ысуллары» темасы буенча белемнәрен арттыру, ныгыту

2. Тема буенча сөйләм күнекмәләрен үстерү

3. Туган телне тирәнтен өйрәнүгә этәргеч бирү


# Сүз ясалу ысуллары



# *Сүз ясагыч кушымча ялгану ысулы (кушымчалау)*

Сүз – чән
Яз –гы
Татар –ча
Кыш – ын
Уй – ла
Хәйлә – кәр
Сыз - ык

# Сүз ясалу ысуллары




# *Сүзләр кушылу ысулы*

Кушма сүзләр

Парлы сүзләр

Тезмә сүзләр

# Сүз ясалу ысуллары



# Фонетик ысул

күз – күр

хәзер – әзер

та'ныш - таны'ш

чачак -чәчәк

# Сүз ясалу ысуллары



**Тәгәри китте йомгагым, күрмәдегезме, агайлар**

**Рәсем конкурсына йомгак ясалды**

Ай сүзен төрле мәгънәдә кулланып, җөмләләр төзегез.

# Сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү ысулы

Яңа сүзләр кулланылышта булган сүзләрнең мәгънәләре үзгәреп ясала

Йомгак(җеп чорнамы) - йомгак(нәтиҗә)

Ай(күк җисеме) – ай(вакыт берәмлеге)

Тамыр(үсемлек өлеше) – тамыр(сүзнең мәгънәле кисәге)

# Сүз ясалу ысуллары

- сүз ясагыч кушымча ялгану
- сүзләр кушылу
- фонетик ысул (аваз составын үзгәртү
- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү

# *Сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү ысулы*






**буяу (нәрсә?)- исем**

**сорау**

**карт**


**буяу ( нишләү?)- фигыль**

**сорау**

**карт**

# Сүз ясалу ысуллары

- сүз ясагыч кушымча ялгану
- сүзләр кушылу
- фонетик ысул (аваз составын үзгәртү
- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү
- сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү


3=С
б

**ТР, драмтүгәрәк, КамАЗ, музфак, КДУ, ПТУ, АКШ**

# Сүзләрне кыскарту ысулы

Яңа сүзләр кулланылыштагы тезмә сүзләрне кыскартып ясала

КДУ
БМО
драмтүгәрәк
медуниверситет

# Сүз ясалу ысуллары

- сүз ясагыч кушымча ялгану
- сүзләр кушылу
- фонетик ысул (аваз составын үзгәртү
- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү
- сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү
- сүзләрне кыскарту

# Тест

## 1.Тезмә сүзләр күрсәтелгән рәтне билгеләгез

1. Җир(җиләге), ял(ит),туган(ил)
2. Ара(тирә), аш(су), хатын(кыз)
3. Кул(яулык), тере(көмеш), таш(күмер)
4. Юл(чы), утын(лык), оял(чан)

## 2. Кушымчалау юлы белән ясалган сүзләр рәтен билгеләгез

1. Кул(яулык), тере(көмеш), таш(күмер)
2. Юл(чы), утын(лык), оял(чан)
3. Бакча, бармак, атла
4. Туган көн, очкылык тоту, бал корты

# 3. Фонетик ысул белән ясалган сүзләр рәтен билгеләргә.

1. Умартачылык, чынбарлык, ташбаш
2. Савыт-саба, бала-чага, тирә-як
3. Идән буяу, буяу алу, китап уку, уку дәресе
4. Хаҗәт-әҗәт, хикәят-әкият, гамәл-әмәл

4. *Ямьле, комлык, эшлә, озынча* сүзләре нинди ысул белән ясалганнар?

1. Сүз ясагыч кушымча өстәү юлы белән
2. Сүзләрне кушу юлы белән
3. Сүзләрне кыскарту юлы белән
4. Сүзгә яңа мәгънә өстәү юлы белән

# 5. *Ераклыктан* сүзенең нигезен билгеләгез

1. Ерак
2. Ераклык
3. Ер
4. Ераклыкта

6. *Бүлмәдәшне* сүзен сүз төзелеше буенча тикшерегез.

# Җавапларны тикшер:

1. 1
2. 2
3. 4
4. 1
5. 2

Бүл – мә –дәш - не

бүл –тамыр

мә – сүз ясагыч кушымча

дәш - сүз ясагыч кушымча

не – бәйләгеч кушымча

# Сүз ясалу ысуллары

- сүз ясагыч кушымча ялгану
- сүзләр кушылу
- сүзләрне бер сүз төркеменнән икенчесенә күчерү
- сүзләрне кыскарту
- фонетик ысул (аваз составын үзгәрту
- сүзләрнең мәгънәсе үзгәрү

**Өйгә эш:  Сүз ясалу ысулларының һәрберсенә икешәр җөмлә уйлап языгыз**